**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 51, с.Утыз Имян, 423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы,423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**19 сентябрь 2019 ел** **№116**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында.**

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Яңа Кади авыл җирлеге Уставы нигезендә, Яңа Кади авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 115 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын, Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 12 номерлы «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 550 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

-Утыз Имән торак пунктында "Чәчәкле алан" чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен кирәкле материаллар сатып алу;
-Утыз Имән торак пунктында һәм Кызыл Чишмә авылында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
-Утыз Имән торак пунктында 1 һәм 4 номерлы зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (койма урнаштыру (ремонтлау), агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә авылларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып алуга, хезмәтләр күрсәтүгә), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
-Утыз Имән авылында 4 данә күләмендә тавыш көчәйткечләр урнаштырырга һәм 3 км озынлыктагы чыбык сузарга;
- Совет урамында урам-юл челтәрен төзекләндерү, Утыз Имән торак пунктында 200 метр (20-30 мм фракциясендә вак таш сатып алу);
-Утыз Имән авылының 1 нче һәм 2 нче скважиналарын лицензияләү өчен түләү.

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында бастырып чыгарырга һәм рәсми хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы,
Яңа Кади авыл җирлеге Советы рәисе Әминов М. М.